ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3.03.2023 г.Лениногорск №125

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәренә җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм «Көндәшлекне яклау турында»Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 19 декабрендәге 541-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында»Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәренә җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

27 статьяның 5 өлешен түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.1) капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килешү, әгәр мондый килештерү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган булса;» ( 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә);

28 статьяның 7 өлешендә «башкарма документлар составы һәм аларны алып бару тәртибе,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны рәсми публикаторда, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры — Р.Г. Хөсәенов